**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5733**
**30.10.2020**

«2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында

Яр Чаллы шәһәрендә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау буенча тормышка ашырыла торган чараларның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү максатында, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасын тормышка ашыру чараларын финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетында каралган акчалар хисабына 250 мең сум: 2021 елда – 50 мең сум; 2022 елда – 50 мең сум; 2023 елда – 50 мең сум; 2024 елда – 50 мең сум; 2025 елда – 50 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 30 октябрендәге
5733 номерлы карарына
кушымта

«2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау»
муниципаль программасы

# 1 бүлек. «2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасының паспорты

<table>
<tr><td>Программаның исеме</td><td>«2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасы</td></tr>
<tr><td>Программаны эшләү өчен нигез</td><td>«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы</td></tr>
<tr><td>Программаны төп эшләүчеләр һәм башкаручылар</td><td>Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе</td></tr>
<tr><td>Программаның максаты</td><td>Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча тормышка ашырыла торган чараларның сыйфатын күтәрү</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td>1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча эш тәҗрибәсен тарату һәм кертү.<br>2. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар планын тормышка ашыру.<br>3. Социаль куркыныч хәлдә, авыр тормыш шартларында булган балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне иртәрәк ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү системасын үстерү һәм камилләштерү.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>2021-2025 еллар</td></tr>
<tr><td>Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td>Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 250 мең сум тәшкил итә.
<table>
<tr><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="6">Программаны тормышка ашыру еллары, мең сум</td></tr>
<tr><td>2021 (мең сум)</td><td>2022 (мең сум)</td><td>2023 (мең сум)</td><td>2024 (мең сум)</td><td>2025 (мең сум)</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>50</td><td>50</td><td>50</td><td>50</td><td>50</td><td>250</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>50</td><td>50</td><td>50</td><td>50</td><td>50</td><td>250</td></tr>
</table></td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка</td><td>Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2025 елда түбәндәгеләр күздә тотыла:</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 1) балигъ булмаганнар арасында җинаятьчелекне кимetү;<br>2) хокук бозган, җәмәгать тәрбиячеләре беркетелгән балигъ булмаганнарның санын арттыру;<br>3) балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау буенча шәһәрнең массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендәге төркемнәрдә урнаштырылган материалларның санын арттыру;<br>4) профилактик исәптә торган, профильле сменаларга җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның санын арттыру;<br>5) иң яхшы профилактика отряды конкурсында катнашучы белем бирү оешмаларының санын арттыру;<br>6) профилактик исәптә торган, спорт чараларына җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның санын арттыру;<br>7) профилактик исәптә торган, түгәрәкләрдә, секцияләрдә, кызыксыну буенча берләшмәләрдә шөгыльләнүгә җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның санын арттыру;<br>8) хокук бозган, «Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә җибәрелгән балигъ булмаганнарның санын арттыру;<br>9) каникул вакытында балигъ булмаганнар арасында җинаятьләр санын кимetү;<br>10) социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдә тормыш сыйфатын яхшырту;<br>11) «Яшьләр ышаныч телефоны» балалар һәм яшьләр өчен телефон аша экстрен психологик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә мөрәҗәгать итүчеләр санын арттыру;<br>12) социаль куркыныч хәлдә булган, эш белән тәэмин ителгән балигъ булмаганнарның (14-17 яшь) санын арттыру;<br>13) «Мәктәп татулашу хезмәте» проектына җәлеп ителгән белем бирү оешмаларының санын арттыру. |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Программаның үтәлешенә контрольне Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе гамәлгә ашыра |

2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

«2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасы (алга таба – программа) Яр Чаллы шәһәрендәге җинаятьчелекнең гомуми торышын исәпкә алып эшләнде.

Хәзерге вакытта профилактик исәпләрдә 571 балигъ булмаган яшүсмер тора (узган (2019) елның аналогик күрсәткече (алга таба – УЕАК) – 575), шуларның социаль куркыныч хәлдә булганнары – 235. 2020 елда балигъ булмаганнар кылган җинаятьләр арасында төп масса мөлкәтне яшерен урлашуга һәм явыз ният-көчләү составына туры килә. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, шартлы рәвештә хөкем ителгән балигъ булмаганнар тарафыннан җинаятьләр кылу тугыздан җидегә кадәр кимегән, ә полициянең профилактик исәбендә торучылар тарафыннан 17 җинаять кылынган (УЕАК – 14). Элек

хөкем ителгән 28 балигъ булмаган яшүсмер (УЕАК – 19) тарафыннан 92 җинаять (УЕАК – 41) кылынган.

Балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне, шул исәптән төркемле җинаятьчелекне профилактикалау эшен оештыру һәрвакыт өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып санала. Әлеге мәсьәлә шәһәрнең барлык хокук саклау органнары, шулай ук җирле үзидарә органнары җитәкчелегенең аерым контролендә тора.

«Лидер» төркеменең Кибердружина белән берлектә эшләве кысаларында, социаль челтәрләрдә җәмгыятькә каршы юнәлештәге төркемнәрне һәм балигъ булмаганнарның деструктив төркемнәрен ачыклау максатында, аларны блокировкалау һәм балигъ булмаганнарның җәмгыятькә каршы һәм деструктив юнәлешләре таралуга юл куймау максатында социаль челтәрләрнең даими мониторингы үткәрелә. Оператив мәгълүматларга караганда, хәзерге вакытта шәһәр территориясендә балигъ булмаганнарның деструктив юнәлештәге 4 төркеме бар: «Белята», «Утята», «Спортсмены», «Треугольник», аларда саны 30 дан артмаган катнашучы гомуми җинаятьләр кыла. Социаль челтәрләрдә әлеге төркемнәр блокировкаланды. 2020 елның 9 аенда 102 җинаять эше (УЕАК – 52) судка җибәрелде.

Узган чорда барлыгы 94 җинаять ачыкланды, кайнар эздән шуның 76 сы ачылды (УЕАК – 51).

Яшүсмерләр җинаятьчелеген кисәтү буенча иң нәтиҗәле эш формаларының берсе булып җинаятьләр кылуга сәләтле балигъ булмаганнарны үз вакытында ачыклау, алга таба аларны «Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының балигъ булмаган хокук бозучыларны  вакытлыча тоту үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә (алга таба – ББХБВТҮ), ябык типтагы махсус уку йортларында изоляцияләү тора.

2020 елның 9 аенда балигъ булмаган 8 яшүсмер ББХБВТҮ гә җибәрелде, 2019 елда – 4 яшүсмер.

2020 елның 9 аенда балигъ булмаганнар белән эшләүче инспекторлар тарафыннан 3997 кеше ачыкланды һәм административ җаваплылыкка тартылды (УЕАК – 2256).

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән 188 рейд үткәрелде, алар барышында ата-аналары яки аларны алыштыручы затлар озатуыннан башка төнге вакытта урамнарда һәм җәмәгать урыннарында булган 404 балигъ булмаган яшүсмер тоткарланды, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.11 статьясы буенча аларның ата-аналарына административ беркетмәләр төзелде.

Шәһәрдә җинаятьчелеккә каршы торуның нәтиҗәлелеген күтәрү өчен хокук бозуларны профилактикалау субъектларының бу юнәлештә бердәм эшләүләрен дәвам иттерү һәм эш гамәлләрен координацияләү таләп ителә.

Югарыда күрсәтелгән фактлар Яр Чаллы шәһәрендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау проблемаларын хәл итүдә программалы-максатчан якын килүне куллану кирәклеген шарт итеп куя.

Программа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өчен ачык булып кала.

## 3 бүлек. Программаның максатлары һәм бурычлары

Программаны тормышка ашыру 5 елга – 2021-2025 елларга исәпләнә.

Программаның максаты булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча тормышка ашырыла торган чараларның сыйфатын күтәрү тора.

Программаның бурычлары:

- Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча эш тәҗрибәсен

тарату һәм кертү;

- сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар планын тормышка ашыру;

- социаль куркыныч хәлдә, авыр тормыш шартларында булган балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне иртәрәк ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү системасын үстерү һәм камилләштерү.

## 4 бүлек. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген билгеләргә мөмкинлек бирә торган индикаторлар

Программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге күрсәткечләрдән файдаланырга тәкъдим ителә:

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү методикасы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1. | Җинаять кылган балигъ булмаганнарның саны, берәмлек | N - сан | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы Идарәсенең балигъ булмаганнар белән эшләү бүлегенең статистик мәгълүматлары |
| 2. | Балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча иң яхшы белем бирү учреждениесе конкурсында катнашучы белем бирү оешмаларының саны, берәмлек | N - сан | Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе хисабы |
| 3. | Җәмәгать тәрбиячеләре беркетелгән балигъ булмаганнарның өлеше, процент | Днов = НОВ / НСУ х 100, монда<br>Днов – җинаять кылган, җәмәгать тәрбиячеләре беркетелгән балигъ булмаганнарның өлеше;<br>НОВ - җинаять кылган, җәмәгать тәрбиячеләре беркетелгән балигъ булмаганнарның саны;<br>НСУ – полициянең профилактик исәпләрендә (алга таба – ППИ) торган һәм социаль авыр хәлдә булган (алга таба – САХ) балигъ булмаганнарның саны | Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең статистик мәгълүматлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау буенча шәһәрнең массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендәге төркемнәрдә урнаштырылган материалларның саны, берәмлек | N - сан | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе, Башкарма комитетның районнар хакимиятләре хисаплары |
| 5. | Ата-аналар университетында үткәрелгән очрашулар саны, берәмлек | N - сан | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе хисабы |
| 6. | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ Идарәсенең ППИ профилактик исәпләрендә (алга таба – ППИ), мәктәпнең эчке исәбендә (алга таба – МЭИ) торган, социаль авыр хәлдә булган (алга таба – САХ), профильле сменаларга җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның өлеше, процент | Днпс = ПС / НСУ х 100, монда<br>Днпс - ППИ, САХ, МЭИ профилактик исәпләрендә торган, профильле сменаларга җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның өлеше;<br>НПС - ППИ, САХ, МЭИ профилактик исәпләрендә торган, профильле сменаларга җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның саны;<br>НСУ - ППИ, САХ, МЭИ профилактик исәпләрендә торган балигъ булмаганнарның саны | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе хисаплары |
| 7. | Иң яхшы профилактика отряды конкурсында катнашучы белем бирүче оешмаларның саны, берәмлек | N - сан | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе хисабы |
| 8. | ППИ, САХ, МЭИ, профилактик исәпләрендә торган, спорт чараларына җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның саны, процент | Днсм = НСМ / НСУ х 100, монда<br>Днсм - ППИ, САХ, МЭИ профилактик исәпләрендә торган, спорт чараларына җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның өлеше;<br>НСМ - ППИ, САХ, МЭИ профилактик исәпләрендә торган, спорт чараларына җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның саны;<br>НСУ - ППИ, САХ, МЭИ профилактик исәпләрендә торган балигъ булмаганнарның саны | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе хисаплары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9. | Профилактик исәпләрдә торган, түгәрәкләрдә, секцияләрдә, кызыксыну буенча берләшмәләрдә шөгыльләнүгә җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның өлеше, процент | Днз = НЗ / НСУ x 100,<br>монда<br>Днз - профилактик исәпләрдә торган, түгәрәкләрдә, секцияләрдә, кызыксыну буенча берләшмәләрдә шөгыльләнүгә җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның өлеше;<br>НЗ - профилактик исәпләрдә торган, түгәрәкләрдә, секцияләрдә, кызыксыну буенча берләшмәләрдә шөгыльләнүгә җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның саны;<br>НСУ - ППИ, САХ, МЭИ профилактик исәпләрендә торган балигъ булмаганнарның саны | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе хисаплары |
| 10. | «Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә җибәрелгән балигъ булмаганнарның саны, берәмлек | N - сан | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы Идарәсенең балигъ булмаганнар белән эшләү бүлегенең статистик мәгълүматлары |
| 11. | Каникул вакытында җинаять кылган балигъ булмаганнарның өлеше, процент | Дсп = НПЛ / Н x 100,<br>монда<br>Дсп - каникул вакытында җинаять кылган балигъ булмаганнарның өлеше;<br>НПЛ - каникул вакытында җинаять кылган балигъ булмаганнарның саны;<br>Н – 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарның саны | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы Идарәсенең балигъ булмаганнар белән эшләү бүлегенең статистик мәгълүматлары |
| 12. | Профилактик исәпләрдә торган, каникул вакытында балигъ булмаганнар арасында кылынган җинаятьләрнең өлеше, процент | Днспу = Нспу / НПЛ x 100,<br>монда<br>Днспу - профилактик исәпләрдә торган, каникул вакытында балигъ булмаганнар арасында кылынган җинаятьләрнең өлеше;<br>Нспу - профилактик исәпләрдә торган, каникул вакытында җинаять кылган балигъ булмаганнарның саны;<br>НПЛ - каникул вакытында җинаять кылган балигъ булмаганнарның саны | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы Идарәсенең балигъ булмаганнар белән эшләү бүлегенең статистик мәгълүматлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13. | Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне индивидуаль реабилитацияләүне тормышка ашыра торган программаларның өлеше, процент | Дрипр = НИПР / ИПР х100, монда<br>Дрипр - социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне индивидуаль реабилитацияләүне тормышка ашыра торган программаларның өлеше;<br>НРИПР – индивидуаль реабилитацияләүне тормышка ашыра торган программаларның саны;<br>ИПР - тормышка ашырыла торган индивидуаль реабилитация программаларының саны | Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең хисабы |
| 14. | Балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе утырышларында карап тикшерелгән һәм программага кертелгән материалларның өлеше, процент | Дмр = РМ / ПМ х 100, монда<br>Дмр - балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе утырышларында карап тикшерелгән һәм программага кертелгән материалларның өлеше;<br>РМ - балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә балигъ булмаганнарга карата кергән, карап тикшерелгән материалларның саны;<br>ПМ - балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә балигъ булмаганнарга карата кергән материалларның саны | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе бүлекләренең хисабы |
| 15. | «Яшьләр ышаныч телефоны» балалар һәм яшьләргә телефон аша экстрен психологик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә мөрәҗәгать итүләр саны, берәмлек | N - сан | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе хисабы |
| 16. | Социаль куркыныч хәлдә булган, эш белән тәэмин ителгән балигъ булмаганнарның (14-17 яшь) өлеше | Дтн = ТН / САХ х 100, монда<br>Дтн - социаль куркыныч хәлдә булган, эш белән тәэмин ителгән балигъ булмаганнарның (14-17 яшь) өлеше;<br>ТН - социаль куркыныч хәлдә | «Яр Чаллы шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ хисабы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | булган, эш белән тәэмин ителгән балигъ булмаганнарның саны;<br>САХ - социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарның саны | |
| 17. | «Мәктәпкә әзерләнергә булыш» акциясе буенча ярдәм алган гаиләләр саны, берәмлек | N - сан | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре хисаплары |
| 18. | Укучы балалары булган, тикшерелгән гаиләләр өлеше, процент | Дбыт = ОШ / Ш х 100,<br>монда<br>Дбыт - укучы балалары булган, тикшерелгән гаиләләр өлеше;<br>ОШ – укучы балалары булган, тикшерелгән гаиләләр саны;<br>Ш – укучы балалары булган гаиләләр саны | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе хисабы |
| 19. | «Мәктәп татулашу хезмәте» проектына җәлеп ителгән белем бирү оешмаларының өлеше, процент | Дшп = ШП / КШ х100,<br>монда<br>Дшп - «Мәктәп татулашу хезмәте» проектына җәлеп ителгән белем бирү оешмаларының өлеше;<br>ШП - «Мәктәп татулашу хезмәте» проектына җәлеп ителгән белем бирү оешмаларының саны;<br>МС – шәһәрдәге белем бирү оешмаларының саны | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе хисабы |

5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

2021-2025 елларга программаны финанслау күләме 250 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча: 2021 елда – 50 мең сум; 2022 елда – 50 мең сум; 2023 елда – 50 мең сум; 2024 елда – 50 мең сум; 2025 елда – 50 мең сум.

6 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелегенә түбәндәгеләр хисабына ирешеләчәк:

- балигъ булмаганнар арасында теркәлгән җинаятьләрнең санын киметү;
- профилактик исәпләрдә торган яшүсмерләр тарафыннан кылынган җинаятьләрнең санын киметү;
- профилактик исәпләрдә торган, берләшмәләр, түгәрәкләр һәм секцияләрдә шөгыльләнүгә җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның санын арттыру.

## 7 бүлек. «2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасының программа чаралары

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, берәмлек | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 (база) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| Максат: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча тормышка ашырыла торган чараларның сыйфатын күтәрү | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 бурыч. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча эш тәҗрибәсен тарату һәм кертү | | | | | | | | | | | | | | |
| 1. Балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикау мәсьәләләре буенча семинарлар, киңәшмәләр оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | 2021-2025 | Җинаять кылган балигъ булмаганнарның саны, берәмлек | 184 | 170 | 150 | 150 | 150 | 150 | - | | | | |
| 2. Балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча иң яхшы белем бирү учреждениесе конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2021-2025 елларның җәйге чоры | Конкурста катнашучы белем бирү оешмаларының саны, берәмлек | 60 | 63 | 65 | 65 | 65 | 65 | - | | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, берәмлек | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 (база) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 3. «Балигъ булмаган яшүсмернең иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе» конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе | 2021-2025 | «Куркыныч төркем» дә торган, җәмәгать тәрбиячеләре беркетелгән балигъ булмаганнарның өлеше, процент | 68 | 69 | 70 | 70 | 70 | 70 | - | | | | |
| 4. «Ата-аналар университеты» оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2021-2025 | Үткәрелгән очрашулар саны, берәмлек | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | - | | | | |
| 5. ППИ, САХ, МЭИ профилактик исәпләрендә торган, «куркыныч төркем» дәге балигъ булмаганнарның ата-аналары өчен җыелышлар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2021-2025 | Җинаять кылган балигъ булмаганнарның саны, берәмлек | 184 | 170 | 150 | 150 | 150 | 150 | - | | | | |
| 6. Шәһәрнең массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендәге төркемнәрдә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау буенча материаллар урнаштыру | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе, Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | 2021-2025 | Шәһәрнең массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендәге төркемнәрдә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау буенча урнаштырылган материаллар саны, | 30 | 32 | 35 | 35 | 35 | 35 | - | | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, берәмлек | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 (база) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| | | | берәмлек | | | | | | | | | | | |
| 2 бурыч. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалауга юнәлтелгән чаралар комплексын тормышка ашыру | | | | | | | | | | | | | | |
| 7. ППИ, САХ, МЭИ профилактик исәпләрендә торган балигъ булмаганнар өчен профильле сменалар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2021-2025 | ППИ, САХ, МЭИ профилактик исәпләрендә торган, профильле сменаларга җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның өлеше, процент | 7 | 8 | 9 | 10 | 10 | 10 | - | | | | |
| 8. Белем бирү оешмалары арасында иң яхшы профилактика отряды конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2021-2025 | Иң яхшы профилактика отряды конкурсында катнашучы отрядлар саны, берәмлек | 60 | 62 | 64 | 64 | 64 | 64 | - | | | | |
| 9. ППИ, САХ, МЭИ профилактик исәпләрендә торган балигъ булмаганнар өчен спорт чаралары үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2021-2025 | ППИ, САХ, МЭИ профилактик исәпләрендә торган, спорт чараларына җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның өлеше, процент | 80 | 85 | 90 | 90 | 90 | 90 | - | | | | |
| 10. ППИ, САХ, МЭИ профилактик исәпләрендә торган балигъ булмаганнарның түгәрәкләрдә, секцияләрдә, кызыксынулар буенча берләшмәләрдә шөгыльләнүен | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | 2021-2025 | Профилактик исәпләрдә торган, түгәрәкләрдә, секцияләрдә, кызыксынулар буенча берләшмәләрдә шөгыльләнүче балигъ булмаганнарның | 72 | 73 | 74 | 74 | 74 | 74 | - | | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, берәмлек | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 (база) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| оештыру | | | өлеше, процент | | | | | | | | | | | |
| 11. Балигъ булмаганнарны «Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә җибәрү | Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе | 2021-2025 | «Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә җибәрелгән балигъ булмаганнарның саны, берәмлек | 4 | 6 | 8 | 8 | 8 | 8 | - | | | | |
| 3 бурыч. Социаль куркыныч хәлдә, авыр тормыш шартларында булган балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне иртәрәк ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү системасын үстерү һәм камилләштерү | | | | | | | | | | | | | | |
| 12. Ел саен уздырыла торган «Яшүсмер» ведомствоара профилактика операциясен үткәрү | Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек бүлеге | 2021-2025 елларның җәйге чоры | Каникул вакытында балигъ булмаганнар арасындагы җинаятьләрнең өлеше, процент | 0,05 | 0,046 | 0,044 | 0,044 | 0,044 | 0,044 | - | | | | |
| 13. ППИ, САХ, МЭИ профилактик исәпләрендә торган | Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән | 2021-2025 | Профилактик исәпләрдә торган балигъ | 0,05 | 0,046 | 0,044 | 0,044 | 0,044 | 0,044 | - | | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, берәмлек | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 (база) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| укучылар белән каникул вакытында эшне оештыру | эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | | булмаганнар арасында каникул вакытында кылынган җинаятьләрнең өлеше, процент | | | | | | | | | | | |
| 14. «1С системасы: 8.0 предпрятие «1.0 Балигъ булмаганнар белән эшләү комиссиясе» программасында балигъ булмаганнарга, аларның ата-аналарына һәм башка затларга карата кергән административ материалларның бердәм исәп базасын булдыру | Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе | 2021-2025 | Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе утырышларында карап тикшерелгән һәм программага кертелгән материаллар өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 |
| 15. Ел саен уздырыла торган «Мәктәпкә әзерләнергә булыш» акциясен оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2021-2025 елларның җәйге чоры | Ярдәм алган гаиләләр саны, берәмлек | 761 | 900 | 1000 | 1000 | 1000 | 1000 | - | | | | |
| 16. Ел саен уздырыла торган «КӨНКҮРЕШ» операциясен оештыру | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2021-2025 | Укучы балалары булган, тикшерелгән ата-аналар, процент | 82 | 83 | 84 | 85 | 85 | 85 | - | | | | |
| 17. «Татарстан Республикасында | Башкарма комитет карамагындагы балигъ | 2021-2025 | Социаль-куркыныч хәлдә | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, берәмлек | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 (база) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| социаль-куркыныч хәлдә булган балаларны һәм аларның гаиләләрен исәпкә алу һәм мониторинг» мәгълүмат системасындагы профилактика системасы субъектларының эш нәтиҗәлелеген мониторинглауны оештыру | булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек бүлеге | | булган гаиләләрне индивидуаль реабилитацияләүне тормышка ашыра торган программаларның өлеше, процент | | | | | | | | | | | |
| 18. «Яшьләр ышаныч телефоны» балалар һәм яшьләр өчен телефон аша экстрен психологик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең эшен оештыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2021-2025 | «Яшьләр ышаныч телефоны» балалар һәм яшьләр өчен телефон аша экстрен психологик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә мөрәҗәгать итүләрнең саны, берәмлек | 6000 | 6500 | 7000 | 7000 | 7000 | 7000 | - | | | | |
| 19. Социаль-куркыныч хәлдә булган балаларның каникул | Башкарма комитет карамагындагы балигъ булмаганнар белән | 2021-2025 | Социаль куркыныч хәлдә булган, эш белән | 45 | 50 | 60 | 60 | 60 | 60 | - | | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, берәмлек | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 (база) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| вакытындагы мәшгульлеген, ялын һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру | эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | | тәэмин ителгән балигъ булмаганнарның (14-17 яшь) өлеше, процент | | | | | | | | | | | |
| 20. «Мәктәп татулашу хезмәте» проектын оештыру | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2021-2025 | «Мәктәп татулашу хезмәте» проектына җәлеп ителгән белем бирү оешмалары өлеше, процент | 13 | 55 | 70 | 80 | 80 | 80 | - | | | | |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева